| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 15.03.2019 | Казан ш. | № 6-2/тп |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019 елга тоташтырыла торган җылылык басымы куәтенең бер берәмлегенә исәпләгәндә «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы җылылык челтәрләре филиалының җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 2018 елның 26 октябрендәге 6-169/тп номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылы белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау), җылы белән тәэмин итү өлкәсендәге хезмәтләрдән дискриминацион булмаган файдалану мөмкинлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм көчләрен югалткан дип тану турында» 2018 елның 5 июлендәге 787 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) хисаплап чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019 елга тоташтырыла торган җылылык басымы куәтенең бер берәмлегенә исәпләгәндә «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Яр Чаллы җылылык челтәрләре филиалының җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 2018 елның 26 октябрендәге 6-169/тп номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

«кушымтага» сүзен «1 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

«Техник тоташтыру мөмкинлеге булганда мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган объектының җылылык йөкләнеше сәгатенә 1,5 Гкал артып киткән очракта, тоташтырылга торган җылылык йөкләнешенең куәт бирәмлегеннән хисаплап, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы Яр Чаллы җылылык челтәрләренең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруга (технологик ялгауга), шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, түләү билгеләргә.»;

кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 26.10.2018
№ 6-169/тп карарына 1 нче кушымта»;

түбәндәге эчтәлекле икенче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 26.10.2018
№ 6-169/тп карарына 2 нче кушымта

Техник тоташтыру мөмкинлеге булганда мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган объектының җылылык йөкләнеше сәгатенә 1,5 Гкал артып киткән очракта, тоташтырылга торган җылылык йөкләнешенең куәт бирәмлегеннән хисаплап, «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы Яр Чаллы җылылык челтәрләренең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) түләү

меӊ сум/Гкал/сәг (НДС исәпкә алмыйча)

| № п/п | Аталышы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләрнең объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 3,532 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең техник тоташтыру мөмкинлеге булганда тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 Гкал/сәг артып китүче объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре ясауга (үзгәртеп коруга) (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар, ($П_{2.1}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өсте) салу | |
| 2.1.1 | 50-250 мм | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | – |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал белән салу | |
| 2.2.1.1 | 50-250 мм | 2 917,623 |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | каналсыз итеп салу | |
| 2.2.2.1 | 50-250 мм | - |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең техник тоташтыру мөмкинлеге булганда тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 Гкал/сәг артып китүче объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар ($П_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | -» |

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе А.С.Груничев